ИКЕНЧЕ МӨМКИНЛЕК

Яшәр урыннары булмаган кешеләргә ярдәм чаралары әзерләнә

> 2

РУХИ ДАРУ

Театр балаларны интернет бәйлелегеннән коткарырмы?

> 3

ТЕЛЕФОНДА – АВЫЛ

Татар телле блогерлар бәйгесе җиңүчеләре бүләкләнде

> 3

РӘХМӘТ, ТАБИБ!

Регина Корбанованың «таҗлы» көндәлеге

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 14 (28787) | Сишәмбе | 1 февраль | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

«ОМИКРОН»ЛЫ ГЫЙНВАР

Вазгыять

Соңгы бер тәүлектә – 698 очрак! Татарстанда бер көн эчендә коронавирус йоктыручылар саны буенча әнә шундый антирекорд куелды. Республикада бер атна эчендә коронавирус йоктыручылар саны өч тапкыр арткан дигән сүз бу. Россия күләмендә бер тәүлек эчендә ковид йоктыручылар саны 98 меңнән арткан. Мондый хәлнең пандемия башланганнан бирле күзәтелгәне булмаган. Коронавирусның яңа «омикрон» штаммы пәйда булу белән коронавирус әнә шундый зур тизлектә тарала башлады.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Тавыш карлыгу сагайтсын

Хәзерге вакытта республикада 37 кеше коронавирусның «омикрон» штаммын йоктырган. Татарстан буенча Роспотребнадзор идарәсе мәгълүматларына караганда, аларның 31ендә бу чир ОРВИ рәвешендә узса, калганнары аны бернинди билгеләрсез генә үткәргән. Атна азагында Хөкүмәт йортында узган киңәшмәдә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов алдагы ике атнаның бик киеренке булачагын искәртте. «Бер атна эчендә Татарстанда коронавирус йоктыручылар саны өч тапкыр артты. Бу «омикрон» штаммы таралу белән бәйле. Алдагы ике атна шактый киеренке булачак. Без моңа әзер булырга тиеш», – диде Президент.

Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш терапевты, Республика клиник хастаханәсенең терапия клиникасы башлыгы Диана Габделганиева сүзләренә караганда, коронавирусның яңа «омикрон» штаммы алдагыларыннан шактый аерыла.

– Гадәттә, коронавирус йоктырган кеше ис, тәм сизми башлый. Ләкин «омикрон» штаммы вакытында бу сирәк күзәтелә. Аның тагын бер үзгә билгесе бар. Ул да булса – тавыш карлыгу. Кеше кисәк кенә тавышы карлыгуны күп сөйләү яки салкында озак итеп сөйләшеп тору нәтиҗәсе дип уйларга мөмкин. Чынлыкта исә ул шушы җитди авыруның бер билгесе булып чыга. Тора-бара кешенең тамагы да авырта башлый. «Омикрон» штаммы, нигездә, өске сулыш юлларына зыян сала, – дип сөйләде табиб.

Коронавирусның яңа штаммы бик зур тизлектә таралуы, йогышлы булуы белән дә аерыла. «Вектор» вирусология һәм биотехнологияләр фәнни үзәгенең Екатеринбург филиалы җитәкчесе Александр Семенов берничә көн элек шундый белдерү белән чыкты. Белгеч сүзләренә караганда, аны эләктергән кеше инфекцияне берничә сәгатьтән соң ук башкаларга да йоктыра. Коронавирусның башка штаммнарына моның өчен өч-дүрт көн вакыт кирәк. Шуңа күрә соңгы бер атна эчендә хастаханәләрнең авырулар белән шыплап тулуына, «ашыгыч ярдәм» хезмәтенә шалтыратуларның тынып тормавына да аптырарлык түгел.

«Үзлегеңнән генә дәваланырга ярамый. Ике көн дәвамында 38,5 температура саклανса, кеше авырдан суласа, кичекмәстән «ашыгыч ярдәм» чакыртырга кирәк», – ди Диана Габделганиева. Тән температурасы 37 тирәсендә генә тирбәлсә, чаң сугарга кирәкми, билгеле. Хәзерге вакытта даруханәләрдә кеше коронавирус белән авыраймы-юкмы икәнлекне бер мизгелдә ачыкларга ярдәм итүче экспресс-тестлар сатыла. Татарстанның баш терапевты ул һәр гаиләдә запаста торырга тиеш дигән фикердә. Әлеге экспресс-тест уңай нәтиҗә күрсәтсә, бу хакта теркәлү урыны буенча хастаханәгә хәбәр итәргә кирәк. «Шундый чорда яшибез: борынга сала, температураны төшерә торган дарулар һәрчак кул астында торырга тиеш», – ди Диана Габделганиева. Көн дәвамында чиста су эчеп, бүлмәләрне җилләтеп торырга да онытмаска кирәк. Антибиотикларны фәкать табиб кушуы буенча гына эчәргә кирәк.

Бала да авыр кичерә

Соңгы арада балалар да коронавирусны авыррак кичерә башлаган. Гыйнварның соңгы ункөнлегендә республикада коронавирус йоктырган балалар саны 11 тапкыр (!) арткан. Белгечләр моны әлеге дә баягы «омикрон» штаммы таралу белән бәйләп аңлата.

Республика клиник балалар хастаханәсе табиб-пульмонологы Илнур Закиров сүзләренә караганда, бүген биредәге ковид госпиталендә 80ләп бала дәвалана. Алар арасында ИВЛ аппаратына тоташтырылганнары юк. Әмма кислород маскасы киеп дәваланырга мәҗбүр булган балалар шактый икән. «Коронавирусның «омикрон» штаммы пәйда булу белән балалар ешрак авырый башлады. Бер яшькә кадәрге балалар арасында хастаханәгә эләгүче сабыйлар аеруча күп. Бала тудыру йортыннан турыдан-туры безгә китерелгән нарасыйлар да бар», – ди Илнур Закиров.

Ахыры 2 нче биттә >

Халык саны кими

Узган елда Россиядә үлүчеләр саны туучыларга караганда 1 миллион кешедән артып киткән. Бүгенге Россия Федерациясе тарихында беренче тапкыр шундый зур сан бу. Соңгы тапкыр әлеге күрсәткеч 2000 елда шул чама булган. Төп сәбәбе – пандемия. Росстат мәгълүматларына караганда, 1 гыйнварга илдә халык саны, бер ел эчендә чама белән 693 мең кешегә кимеп (минус 0,5 процент), 145,478 миллион кеше тәшкил иткән. Моңа кадәр 2002 елда шундый зур күрсәткеч (686 мең кеше үлгән) теркәлгән.

Тулаем алганда, инде менә дүртенче ел рәттән үлүчеләр саны туучыларга караганда артыграк. Шушы вакыт эчендә илдә яшәүчеләр саны 1,4 миллион кешегә кимегән.

Миллиардлаган бурыч бар

1 гыйнварга Татарстанда яшәүчеләрнең торак-коммуналь хезмәтләргә бурычы 8 миллиард сумга җиткән. Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Марат Айзатуллин белдергәнчә, бурыч күләме әлеге хезмәтләр өчен 2 айлык түләү күләменә тигезләшкән. 6 муниципаль берәмлектә түләмәү вакыты ике айдан артып киткән, 20сендә – бер айдан ике айга кадәр. 19 районда торак-коммуналь хезмәтләргә әҗәт бер ай чамасы җыела.

1 гыйнварга газ өчен түләнелмәгән бурыч күләме, бер елда 4,9 миллион сумга артып, 367 миллион сум тәшкил иткән. Декабрьдә бурыч күләме 13,6 миллион сумга кимегән. Барлыгы 14 районда яшәүчеләр әҗәтле, тугызында бурыч күләме тагы да үскән. Шул ук вакытта электр уты өчен бурыч 39 миллион сумга кимегән.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Таләпләрне үтәмәүчеләргә – штраф

Роспотребнадзор идарәсе гыйнвар аенда сәнәгать, транспорт, җәмәгать туклануы, сәүдә, медицина, мәгариф өлкәләрендә барлыгы 722 оешманың коронавируска каршы чараларны ничек үтәвен тикшергән. Ведомство эпидемиягә каршы өстәмә чаралар үткәрү таләбе белән 408 күрсәтмә биргән. Барлыгы 168 оешманың ковидка каршы таләпләрне үтәмәве ачыкланган. Бигрәк тә сәүдә оешмаларында мондый хәлләр еш күзәтелгән. Хезмәткәрләрнең битлексез эшләве, социаль дистанция саклау өчен идәндә сызыклар, һаваны зарарсызландыру җайланмасы булдырмау, хезмәткәрләрнең тән температурасын үлчәмәү, антисептиклар кулланмау кебек кимчелекләр аеруча күп билгеләнгән.

Нәтиҗәдә ведомство административ хокук бозу турында 89 беркетмә төзеп, барлыгы 1 миллион сумнан күбрәк штраф салган. Бер объектның эшчәнлеге 10 тәүлеккә туктатылган.

Ай башында җылы булачак

Синоптиклар әйтүенчә, февральнең беренче атнасы җылы булачак. Көн саен урыны белән явым-төшем көтелә. Чәршәмбе – 2 февральдә республикада иртән һәм төнлә кар-буран. Көндез – урыны белән кар, һава температурасы 0...–5 градус чикләрендә тирбәләчәк. Төнлә –3...–8 градус суык. Пәнҗешәмбедә урыны белән көчле кар-буран, секундына 17 метр тизлектә көчле җил. Көндез һава температурасы –3...+1 градус булачак. Төнлә –3...–8 градус салкын.

Гидрометеоүзәкнең башлангыч мәгълүматларына караганда, җомга һәм шимбә көннәрендә җылы һава саклана, тагын кар явачак. Җомга көнне көндез термометрның терекөмеш баганасы 0...–5 градустан түбән төшмәячәк, төнлә –3...–10 градус булачак. Шимбә көнне көндез –3...–8, төнлә –10 градуска кадәр суыту көтелә.

Актуаль тема

Бөтен гомергә

2021 ЕЛДА ТАТАРСТАНДА ӨЙЛӘНЕШҮЧЕЛӘР САНЫ АРТКАН

Җан яраткан бер генә һәм гомергә булырга тиеш. Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсенең еллык коллегиясендә барыбыз өчен дә билгеле булган кагыйдәне кабат искә төшерде. «Ныклы гаилә – ныклы ил бит ул. Судка барып җиткәч түгел, гаиләне аңа кадәр сакларга кирәк», – дип саный парламент җитәкчесе.

Ул яктан хәлләр тәртиптә икән. Татарстан, элеккечә, гаилә-демографик үсеш юнәлешендә Идел буе федераль округындагы төбәкләр арасында иң яхшы күрсәткечләргә ия. Идарә башлыгы Гөлшат Нигъмәтуллина сүзләренчә, республика берничә юнәлеш буенча алда бара.

Әйтик, былтыр никахлашучылар саны 27 процентка арткан: 24,6 мең кеше тормыш корган. Бу, 2020 ел белән чагыштырганда, 5303 парга күбрәк.

Бәби алып кайткан гаиләләр саны да күп: узган ел республика гаиләләрендә 15796 – икенче, 7676 – өченче, 2523 дүртенче сабый дөньяга килгән. 2008 елдан бирле ишле гаиләләр саны арта бара. Татарстанда хатын-кызлар беренче баласын, уртача алганда, 29 яшьтә алып кайта.

Балигълык яшенә җитмәгән балалары булган гаиләләрдә аерылышу очраклары да кимегән. Бу уңай үзгәрешне икенче ел теркиләр инде. «2019 елда мондый гаиләләр 11628 булса, узган елгы күрсәткеч – 9585. Кимү дәрәҗәсе 17,6 процентны тәшкил итә», – диде ЗАГС идарәсе башлыгы. 1 мең никахка 603 аерылышу очрагы туры килә икән. Чагыштыру өчен: Киров өлкәсендә бу сан – 844, Саратовта – 812, Мари Илендә – 805.

Шул ук вакытта, узган ел аерылышуларның 79 процентын суд хәл иткән, ягъни ир белән хатын әлеге процесста катнашмаган, араны читтән торып кына өзгәннәр. «Бу эш шулай тиз һәм формаль булмасын иде. Аерылышуга барып җиткәнсең икән, бу эштә ике як та катнашырга тиеш», – диде Гөлшат Нигъмәтуллина.

Аннан килеп, аерылышуга бәйле сорау төрле җирдә төрлечә хәл ителгәне ачыкланды. Әйтик, Казан, Кукмара, Яңа Чишмәдә аерылышу турында карарларның яртысыннан артыгы читтән торып кына кабул ителгән. Чагыштыру өчен: Әгерҗе, Әлки, Әлмәттә гаилә мөнәсәбәтләрен читтән торып өзүчеләр күрсәткече нибары 2 процентны тәшкил иткән.

Күңелсез саннарны дәвам итеп, идарә башлыгы үлүчеләр санын да яңгыратты. Идел буе федераль округы буенча карасаң, Татарстанда 1 мең кешегә 15,5 үлем очрагы туры килә һәм бу иң түбән күрсәткеч булып санала. «Билгеле, пандемиягә бәйле вазгыять тә борчу тудырмый калмый», – диде бу җәһәттән Гөлшат Нигъмәтуллина.

Былтыр ЗАГС идарәсе Бердәм дәүләт реестрында саклаган мәгълүматларның сыйфатын арттыру юнәлешендә шактый эш башкарган. Әйтик, 2020 елда идарә реестрга 13 млн гражданлык хәле акты турында мәгълүмат тапшырган. Шуларның 645 меңе – татар телендә. Татарстан Дәүләт архивына 1921–1925 елларда төзелгән актлар китапларын тапшырганнар. «Бу безнең өчен гадәти бер вакыйга гына түгел. Бу – ЗАГС идарәсендә сакланган шулкадәр күләмдәге мәгълүматның 100 процентка электрон рәвешкә күчүен аңлата», – диде Гөлшат Нигъмәтуллина.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Рамил САЛИХОВ, Татарстан Республика клиник хастаханәсенең 1 нче ортопедия бүлеге мөдире:

Табиблар һәрвакыт кирәк. Моның шулай икәнен пандемия дә бик ачык күрсәтте. Бәлки безнең кайчан да булса машина йөртүчеләребез, икътисадчыларыбыз, бухгалтерларыбыз булмас. Ә менә табибсыз яшәү мөмкин түгел. Бу өлкәдә машина берничек тә кешене алыштыра алмый.

(«Реальное время» интернет басмасына әңгәмәдән)

ТАТАРСТАНДА – ГТО КОМПЛЕКСЫ

2021 елда Татарстанда 218220 ГТО билгесе тапшырылган.



Алтын	Көмеш	Бронза
57419	80185	80616

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

САНКЦИЯЛӘР БЕЛӘН КУРКЫТУ ДӘВАМ ИТӘ

Үткән атна яңалыклары гадәттәгечә Украина тирәсендәге вазгыятьне катлауландыруга корылды. Лидерларга бу мәйдандагы җәнҗал ошап китте, күрәсең. Көнбатыш илләре барлык тышкы сәясәтләрен шул проблемага юнәлтте.

Отставкадагы төрек контр-адмиралы, төрек диңгез пехотасына нигез салучы Җиһат Яйҗи АКШ – Россия каршылыгын ясалма каршылык дип бәяләде һәм: «АКШ һәм Россия Казахстан, Сүрия, Украина буенча үзара килешеп эш итәләр. Мин АКШ һәм Россия дошманнар дип уйлаган кешеләрне беркатлы романтиклар дип табам», – дип белдерде. Аның белдерүендә хаклык бардыр, бәлки, әмма үзара килешеп мөнәсәбәтләрне киеренкеләндерү һәм кан коюлы сугыш оештырырга омтылу бер дә сөендерми бит әле монда. Россиянең тышкы эшләр министры Лавров әфәнде үткән атнада Россия белән Украина арасындагы сугышны мәгънәсез дип табуы, Мәскәүдән торса, сугышның башланмаячагын белдерүе белән киеренкелекне берникадәр йомшартты. Россиянең фонд базарында котировкаларны берникадәр өскә күтәрде ул сүзләр, сум да долларга карата бераз ныгыды.

Әмма гаскәрләр әле һаман да хәрәкәттә. Россиянең Әнкарадагы илчесе Алексей Ерхов төрек газетасы Daily Sabahта: «Йөз меңнән артык рус гаскәрен санйсыз, ә ни өчен украин армиясендә күпме «Байрактар» барлыгын исәпләмисез», – дигән эчтәлектәге язма бастырды. Яклар гаскәрләрнең капма-каршы туплануында бер-берсен гаепләүләрен дәвам итә. Көнбатыш бу уңайдан Россияне сугыш башланган очракта кертеләчәк санкцияләргә өстәмә санкцияләр белән куркыта. Бу атнаның дүшәмбесендә британ парламенты Кремль белән бәйле олигархларга һәм компанияләргә санкцияләр кертү турындагы киңәйтелгән исемлекне карарга тиеш. Океан артыннан да Россия банкларына һәм әҗәт кәгазьләренә тыюларны киңәйтү, хәтта кайберләрен сугыш башланганчы ук кертү турында янаулар ишетелә.

Рәсми Киев, Мәскәү шикелле үк, сугыш куркынычы кими дигән фикердә. Франциядә ике ил дипломатлары немец һәм француз сәясәтчеләре катнашында сөйләшүләр алып барды һәм Донбасста утны туктату турында килешүгә ирештеләр. Байден исә шул сөйләшүләр барган чакта Зеленскийга шалтыратып, аны ваемсызлыкта гаепләде, Мәскәү сугыш башларга җыена, дип куркытырга тырышты.

Рәсми Лондон да хәлне катлаулы дип бәяләү ягында. Россияле олигархларны күчемсез милекләрен конфискацияләү белән куркыталар. «Путин олигархлары качар урын таба алмаячак», – дигән рәсми белдерү яңгырады инде. Британ тышкы эшләр министры Лиз Трасс Эстониягә өстәмә хәрби көчләр китерәчәкләрен, Украинаны коралландырачакларын, Кара диңгездән Киевны хәрби очкычлар белән яклаячакларын өзеп әйтте. Тәшвишне көчәйтергә омтылулары аңлашыла, чөнки үткән атна буе Көнбатышта фонд биржасы салмак кына аска таба тәгәрәвен дәвам итте.

Россиядә

БӘЯЛӘРНЕ ЙӨГӘНЛӘҮ ТОРМЫШКА АШАРЛЫКМЫ?

Россиянең эчке тормышында алгы планга бәя сәясәте чыга. Федераль хөкүмәт Премьеры Михаил Мишустин, монополиягә каршы хезмәт (ФАС) җитәкчесе Максим Шаскольский белән очрашып, сәүдә челтәрләре белән эшләү һәм башка тармакларга карата ачылган эшләр турында фикер алышты. Кешеләр һәм бизнес өчен сизелерлек барлык нәрсәнең, барыннан да бигрәк азык-төлек бәяләренең даими контрольдә булырга тиешлегенә басым ясады ул.

Монополиягә каршы федераль хезмәт атна саен илкүләм сәүдә челтәрләрендә, ә төбәк органнары муниципаль сәүдә оешмаларында бәяләрне күзәтеп тора икән. Эре җитештерүчеләргә карата үткәрелгән 165 тикшерү нәтиҗәсендә сигез эш ачылган, 35 кисәтү ясалган. 2021 елның августыннан башлап сәүдә челтәрләрендәге өстәлгән бәяне сөйләшүләр нәтиҗәсендә 22 проценттан 13 процентка кадәр төшерүгә ирешелгән. Сәүдә челтәрләренә товар бәясенә ун проценттан да артык өстәмәскә киңәш ителгән.

ФАС җитәкчесе белдерүенчә, алар күргән чаралар нәтиҗәсендә дару базарында 40 миллиард сумнан ким булмаган бюджет һәм халык акчасы саклап калынган. Соңгы вакытларда гына да 14 мең тормыш өчен әһәмиятле препаратның бәясе каралып, шуның 7 меңенең хакы уртача 30 процентка киметелгән. 27 субъектта даруларның күпләп сату бәясе түбәнәйтелгән, 36 субъектта ваклап сату бәяләре авызлыкланган. Күп кенә төбәкләрдә чүп җыю тарифларын кисәннәр.

Шаскольский әйтүенчә, төзелеш материалларына бәяләрнең кискен үсеше хәтта җинаять эшләре ачуга да китерергә мөмкин икән. Күп кенә эре җитештерүчеләр базар куйган бәяләргә генә риза булмыйча, үзара килешеп бәя күтәргәннәр. Җиде эре металл трейдеры, мәсәлән, шундый адымга барган. Хәзер компанияләр штраф түләячәк, ә аларның җитәкчеләренең эше хокук саклаучыларга тапшырылган.

Монополиягә каршы федераль хезмәт күпме генә тырышмасын, бәяләр барыбер күтәрелә. Кулланучылар һәм җитештерүчеләр сәүдәгәрләрне гаепли, сәүдәгәрләр товар ташучыларны сүгә, ә хакимиятләр исә сәүдә турындагы законны кырысландыру ягына авыша. Хәзергә вазгыять шундый икән: сәүдә челтәрләре китереп җиткерелмәгән товар өчен йөз процентка кадәр штраф сала. Ит җитештерүчеләрнең илкүләм ассоциациясе башкарма комитеты җитәкчесе Сергей Юшин да менә шундый штрафлардан зарлана, сәүдәгәрләр тәэминатчыларга штрафлар ярдәмендә басым ясыйлар, дип бара.

Җитештерүчеләр товар бәясе күтәрелүдә үзкыйммәтне гаепли. Эт – эткә, эт койрыкка сылтый инде ягъни. Авыл хуҗалыгы министрлыгы шуңа күрә сәүдә турындагы законны кырысландыру ягында. Кайбер белгечләр «законның катылыгы аның үтәлмәве белән йомшартыла» дип моңа каршы чыга. Бәяләр исә тарафларның бәхәсе турында берни дә белмичә үсүләрен дәвам итә.

БӨТЕН ГОМЕРГӘ

2021 ЕЛДА ТАТАРСТАНДА ӨЙЛӘНЕШҮЧЕЛӘР САНЫ АРТКАН

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Илдар Мөхәммәтҗанов

Хәзерге вакытта ЗАГС тәкъдим итә торган хезмәтләрнең дә иң мөһимнәре электрон форматка күчерелгән. Цифрлаштыру җәһәтеннән тагын бер яңалыклары бар.

– 2022 елда дәүләт хезмәтләреннән файдалану тармагында алгарыш көтелә. Мәсәлән, теркәлү урынына карамастан, теге яисә бу хезмәттән файдаланырга мөмкин булачак. Кайбер очракларга ЗАГС бүлегенә килеп тору да кирәкми, – диде Гөлшат Нигъмәтуллина.

Алгарышлар янында проблемалар да җитәрлек. Идарә башлыгын районнардагы ЗАГС бүлекләрендә эшләүче хезмәткәрләр саны һәм хезмәт хакы мәсьәләсе борчый.

– Кайбер районнарда ЗАГС идарәсен бер генә хезмәткәр тотып тора. Ялга да китә алмый, авырый калса да, алмаштырыр кеше юк. Шулай ук хезмәтнең матди ягына да игътибар итәсе иде, – диде Гөлшат Нигъмәтуллина.

Идарә башлыгы хисабыннан соң, Татарстан парламенты җитәкчесе телгә алынган саннарга карата үз фикерләрен җиткерде.

Фәрит Мөхәммәтшин, цифрлаштыру тормышның барлык тармакларына үтеп керсә дә, ЗАГС идарәсен традицияләрдән дә читкә тайпылмаска чакырды.

– Никахлашу тантанасы цифрлы форматка күчмәс дип ышанам. Кияү – бер якта, кәләш – башка җирдә, ЗАГС хезмәткәре бүлекчәсендә утыра, ди. Никахны теркәгәндә ул нәрсә дияр? Котлыйм, ир белән хатын булуыгыз турында таныклык «шәхси кабинет»ыгызга юлланды, диярме? Төгәллек, цифрлаштыру бик мөһим ул. Әмма тере аралашу да кирәк. Аны берни алмаштыра алмый. Мин гаиләнең җәмгыятьтәге абруен күтәрү яклы. ЗАГС тарафыннан «алтын», «бриллиант» туйларга җиткән парларны хөрмәтләү кебек чараларны да туктатмаска иде. Андыйлар яшьләргә үрнәк. Аларны күрсәтергә кирәк. Мин дә тормышта бер мәртәбә өйләндем. Сайлап алган тормыш иптәшем Луиза ханым белән безне дә Әлмәттә хөрмәтләделәр. Матур күренеш иде, – диде парламент җитәкчесе. – Аерылышулар саны да борчымый түгел. Бу күренеш балалары булган гаиләләргә аеруча нык тәэсир итә. Бер, ике, өч тапкыр гаилә корып була. Әмма яңа никах гел дә уңышлы булмый ул.

Ул гына да түгел, Фәрит Мөхәммәтшин утырышта катнашучыларга «брак» урынына башка сүз уйлап табарга тәкъдим итте.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

«Омикрон»лы гыйнвар

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Белгеч сүзләренә караганда, тән температурасы 39 градустан да югарырак күтәрелгән сабыйлар кичекмәстән хастаханәгә салына. Үсмерләрне исә температурасы өч көннән соң да төшмәгән очракта шундый язмыш көтә. Моннан тыш, тәнен көзән җыерган, авырдан сулаган, бугазы тарайган балалар да иң беренче чиратта хастаханәгә салына. «Баштарак коронавирус вакытында балалар эч китүдән тилмерә иде. Хәзер исә аларның тән температурасы күтәрелеп аптырата. Аны тиз генә төшерерлек тә түгел. «Омикрон» штаммы йоктырган балаларда үпкә җәрәхәтләнү очраклары да азрак. Ул күзәтелгән очракта да зарарлану дәрәҗәсе 25 проценттан да артмый», – ди Илнур Закиров. Табиб ата-аналарга беренче 3 тәүлектә балада күзәтелгән билгеләргә аеруча игътибар итәргә куша. «Омикрон» котырган чорда артык авырлыктан интеккән, йөрәгенә операция кичергән, ДЦП диагнозлы, бавыры авырткан балалар сәламәтлегенә аеруча игътибарлы булырга кирәк, ди белгеч.

Дистантка күчмибез

Игътибарлы булу, димәктән, атна азагында Хөкүмәт йортында узган киңәшмәдә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та ата-аналарны бу көннәрдә аеруча уяу булырга чакырды. Президент, авырып, мәктәпкә бара алмаган бала җәмәгать урыннарында да йөрмәскә – өйдә генә утырырга тиеш дигән фикердә. «Мәктәпләрне дистанцион рәвештә укуга күчерергә җыенмыйбыз. Әмма мәктәпләрдә иртәнге фильтрлар эшләргә тиеш. ОРВИ ачыкланган класслар карантинга ябылырга тиеш», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Сүз уңаеннан, бу көннәрдә Татарстанда 12–17 яшьлек балаларга коронавируска каршы вакцина ясый башладылар. Хәтерләсәгез, узган елларда республикага 2880 доза «Спутник М» вакцинасы кайтарылды. Ел дәвамында республикага барлыгы шундый 200 меңнән артык доза вакцина кайтыр дип көтелә. Хәзерге вакытта 193 үсмер ковидка каршы прививка ясаткан инде. Вакцина ясату – ирекле.

«Прививка ясатканнан соң баланың тәне авыртырга, температурасы күтәрелергә мөмкин. Хәлсезлек, сүлпәнлек кебек билгеләр дә күзәтелә ала. Мондый күренеш өч көн дәвамында күзәтелә ала. Моннан куркырга кирәкми», – дип искәртте Илнур Закиров. Хәзерге вакытта Татарстанда 2389942 кеше коронавируска каршы вакцина ясаткан.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Илдар Мөхәммәтҗанов

УТЫНГА КЫТЛЫК ЮК

Урман хуҗалыгы

Татарстан урманчылары шулай ди. Республикада яшәүчеләр 25 елга бер тапкыр – йорт һәм ишегалды корылмалары төзү өчен 100 кубометр, 10 елга бер тапкыр – йорт һәм каралты-курасын төзекләндерү өчен 50 кубометр һәм елга бер тапкыр биналарны җылыту өчен 20 кубометр күләмдә агач әзерли алалар.

– Бу эш бик күптәннән алып барыла. Без агач сорап килгән бер генә кешене дә кире бормыйбыз, – ди Урман хуҗалыгы министрлыгының урманнарны торгызу һәм үрчетү бүлеге башлыгы Тимур Галиев. – Урманнан агач яки утын алырга теләгән кеше министр исеменә шул хакта гариза язарга тиеш. Аннары әлеге кешенең үтенечен үти ала торган урманчылыкны сайлыйбыз. Урыны билгеле булгач, ул кеше белән министрлык арасында килешү төзелә. Исегезгә төшереп китәбез: агач бушлай бирелми. Һәркайсының, төренә карап, үз бәясе бар.

Мамадыш районының Кама урманчылыгы җитәкчесе Альберт Шамилов әйтүенчә, алар урманчылыгыннан агач алучылар, утын кирәк дип килүчеләр шактый икән.

– Узган ел безнең урманчылыкка, утын һәм агач сорап, 121 кеше килде. Болар – күрше-тирә районнарда яшәүчеләр. Кайберәүләр өй сала, икенчеләр янганнан соң ярдәм сорап килә. Кемдер утынын мунчасы өчен тота, өйләрен җылытучылар да бар, – ди ул. – Бездә агач җитәрлек. Корыганы да күп. Ел саен утыртып та торабыз.

Агачның бәясе, искәрткәнчә, аның сыйфатына, төренә карый. Альберт Шамилов әйтүенчә, 20 кубометр усак агачы 100 сум тора. Ә инде чималга яраклы («деловой» агач) 50 кубометр усакның бәясе 4–5 мең сумга төшәргә мөмкин. Бер килгән кеше утынын да, такталыгын да сорап алып китә икән.

Бәяләрнең кыйммәт булмавы авыр хәлдә калган гаиләләр өчен кулай, ди урманчы. Кукмарада яшәүче Алия Фарукшина да, йортлары янгач, урман хуҗалыгы министрыннан ярдәм сораган:

– Бик авыр хәлдә калган идем. Ишегалдындагы ике йортыбыз берьюлы янып бетте. Менә шул чакта мин дәүләт ярдәмен тойдым. Ярты елдан ирем дә вафат булгач, миңа урманчылар кулдан килгәнчә булышты. Агачларны кисеп тә, төяп тә бирделәр. Хәтта өйгә кадәр алып килеп бушаттылар да. Аллага шөкер, урамда калмадык. Агачтан йорт салып кердек.

Агач яки утын алырга теләүчеләр, Татарстан Урман хуҗалыгы министрлыгы сайтына (https://minleshoz.tatarstan.ru/administrativnie-reglamenti.htm) кереп, аның тәртибе, шартлары белән таныша ала. Сүз уңаеннан, 2021 елда республикада яшәүче 2044 кеше әлеге мөмкинлектән файдаланган.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ИКЕНЧЕ МӨМКИНЛЕК

Яңалык

Россия Президенты Владимир Путин хөкүмәткә яңа бурычлар куйды. Ул яшәр урыннары булмаган кешеләрне теркәү механизмын камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләргә кушты. Әлеге үзгәрешләр 1 майга кадәр эшләнеп бетәргә тиеш.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Сукбайларны теркәү аларга пенсия алу, медицина учреждениеләренә мөрәҗәгать итү, сәламәтлекләрен кайгырту мөмкинлеген бирәчәк.

– Без бу хәбәрне бик сөенеп кабул иттек, – ди Татарстан Иҗтимагый палатасы әгъзасы, «Социаль тернәкләндерү һәм адаптация үзәге» генераль директоры Азат Гайнетдинов. – Бик төпле, бик уйланылган эш булачак ул. Бүген бездә хәтта урамдагы этләргә дә тамга салалар. Ә урамда, ташландык йортларда, җылыүткәргеч торбалар өстендә яшәүче кешеләрнең бер хокуклары да юк. Аларның аяк-куллары өшегәч, чери башлый. Авыру эт һәм песиләргә дә ветеринарлар ярдәм күрсәтә. Ә бит болар да, нинди булса да, кеше!

Азат Гайнетдинов әйтүенчә, сукбайларга электрон паспорт бирергә мөмкиннәр. Бу исә аларның күп кенә эшләрен җайга салыр иде.

– Пычрак сукбайларны полиция хезмәткәрләренең дә, «ашыгыч ярдәм» хезмәте белгечләренең дә алып китәселәре килми. Бүген алар белән Казанда без генә шөгыльләнәбез. Мескеннәрне җыябыз, юындырабыз, кирәк булса, табибларга күрсәтәбез. Сукбайлар безгә нинди генә халәттә килми. Күпчелегенә табиб ярдәме кирәк була. Әле ярый «ашыгыч ярдәм» хезмәткәрләре безгә каршы килми. Кешеләр дәвалана, документларын эшлибез. Чынлыкта сукбайлар Казанда гына түгел, Россия буенча да бик күп, ләкин төгәл санын беркем дә әйтә алмый. Бу эшне җайга салуга сукбайларның паспортлары булмау, бер шәһәрдән икенче шәһәргә күчеп йөрүләре комачаулый, – ди Азат Гайнетдинов.

Аның фикеренчә, бу үзгәрешләрнең бер генә начарлыгы да юк.

– Сукбайларның кабаттан тулы хокуклы кеше булып яши башлавының бер начарлыгы да юк. Аларның хокуклары һәм бурычлары барлыкка киләчәк. Кайчандыр бу кешеләрнең барысы да булган, ләкин тормышта абынганнар. Бу – алар өчен икенче мөмкинлек, – ди ул.

Аның сүзләренчә, дәүләтнең сукбайларга йөз белән борылуы, беренчедән, медицина буенча алга китәргә ярдәм итәчәк. Документ алу аларга хастаханәләрдә дәвалануга, инвалидлык алырга, аз күләмдә булса да пенсияләрен рәсмиләштерергә, рәсми рәвештә эшкә урнашырга мөмкинлек бирәчәк:

– Без хәзерге вакытта аларга болай да күңлек эшләр бирәбез. Араларында үзмәшгуль булып теркәлүчеләр дә бар. Үз көчебез белән паспортларын да эшләргә булышабыз. Атна саен ике паспорт эшлибез. Бер документны ясату өчен 2–4 мең сум акча түлибез.

Владимир Путин шулай ук сукбайларга социаль һәм медицина ярдәме күрсәтә торган иҗтимагый оешмаларга өстәмә чаралар уйларга кирәклеген дә әйтте.

– Күңел төшеп киткән мизгелләрдә Аллаһы Тәгалә менә шулай сөендерә, – ди Азат Гайнетдинов. – Хөкүмәт белән бергә эшләсәк, күпкә җиңелрәк булыр иде, әлбәттә. Тагын да яхшырак нәтиҗәләр күрсәтә алыр идек. Бу гамәл башка бик күп авырлыкларны хәл итәргә юл ачар дип өметләнәбез.

Президент карамагындагы Кеше хокукларын яклау советы әгъзасы Марина Әхмәдова фикеренчә, әлеге үзгәрешләр сукбайларның гына түгел, башка төр категориягә керүче кешеләрнең дә тормышларын яхшыртачак.

– Болар – сукбайлар гына түгел, ә гадәти тормыш алып баручы, ләкин төрле сәбәпләр аркасында рәсми рәвештә теркәлү уза алмаучылар да, – ди Марина Ахмедова. – Хокуксызлар һәм сукбайлар тормышында бу чыннан да зур алгарыш булачак. Мондый үзгәрешләр кирәклеге хакында Владимир Путинга очрашу вакытында мин сөйләгән идем. Ләкин минем артта бик күп кешеләр тора. Мин шулай ук киләчәктә йортсызлар өчен хастаханәләр булуына да ышанам.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ТЕЛЕФОННАН КҮРЕНӘДЕР БЕЗНЕҢ АВЫЛ...

«БЛОГЕР.ТАТАР» БӘЙГЕСЕ ҖИҢҮЧЕЛӘРЕН БҮЛӘКЛӘДЕЛӘР

«Татар-информ» / Абдул Фәрхан

Икенче «Блогер.Татар» бәйгесе җиңүчеләре

«ИҢ ЯХШЫ АВЫЛ АККАУНТЫ»
- ✓ Рамил Мөхетдинов (Арча районы Наласа авылы)
- ✓ Рузалия Тимербаева (Балтач районы Алан авылы)
- ✓ Руфия Мөхетдинова (Яшел Үзән районы Урысбага авылы)
- ✓ Гөләндәм Хәлиуллина (Сарман районы Илексаз авылы)
- ✓ Лилия Гарифуллина (Балтач районы Көшкәтбаш авылы)

«АВЫЛ ТУРЫНДА ИҢ ЯХШЫ ПОСТ»
- ✓ Әлмирә Ибраһимова (Кама Тамагы районы Бәби авылы)
- ✓ Айгөл Гатауллина (Кукмара районы Зур Кукмара авылы)
- ✓ Айгөл Бикмөхәммәтова (Түбән Кама районы Түбән Уратма авылы)
- ✓ Ландыш Гарифуллина (Балтач районы Яңа Салавыч авылы)
- ✓ Инсаф Низамиев (Зәй районы Югары Шепкә авылы)

Өченче «Блогер.Татар» бәйгесе җиңүчеләре

БЛОГЕРЛАР ҺӘМ МЕДИАШӘХЕСЛӘР:
- ✓ Айгөл Тимер
- ✓ Айваз Садыйров
- ✓ Эльмира Сираҗи
- ✓ Алсу Нургатина
- ✓ Гөлүсә Батталова

ШӘХСИ АККАУНТЛАР:
- ✓ Эльмира Гарипова
- ✓ Мөхәрәм Мөхәммәтҗанов
- ✓ Нурия Шәрәфетдинова (Кыргызстан)
- ✓ Нурия Сираҗиева
- ✓ Фәния Зиннәтшина

Ниһаять, очраштылар. Узган елның 10 сентябрендә һәм быел 15 гыйнварда «Блогер.Татар» икенче һәм өченче бәйгеләренең нәтиҗәләре игълан ителгән иде. Узган атнада Казанда җиңүчеләрне бүләкләделәр.

Икенче «Блогер.Татар» бәйгесе татар авыллары тормышына багышланган булса, өченчесе гаилә темасы белән бәйле иде. Авыл белән бәйле бәйгегә 100дән артык автордан 200гә якын эш килгән. Өченчесендә исә – 150гә якын катнашучыдан 320 эш. Араларында яшьләр дә, өлкәннәр дә бар. Бәйгедә катнашучыларның географиясе дә киң: Казан, Татарстан районнары, Башкортстан, Чечня, Чиләбе, Иркутск һ.б. төбәкләр, хәтта чит илләр дә бар.

Жюри әгъзалары бәйгегә җибәрелгән постларга гына түгел, ә катнашучыларның аккаунтларына да игътибар биргән. Эчтәлекнең кызыклы, үзенчәлекле булуы, иҗади якын килү, татар теленең камиллеге, фото һәм видеоның сыйфаты, даимилек, аудиториянең активлыгы да исәпкә алынган.

Татарстан Президенты каршындагы Туган телләрне саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе җитәкчесе Марат Әхмәтов исеменнән җиңүчеләрне Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Айрат Зарипов сәламләде.

– Татар телле блогерлар күп булу бик сөендерә. Гомумән, интернетта татар теле күп булырга тиеш. Сез бик зур эш алып барасыз. Язылучыларыгыз, караучыларыгыз артып торсын. Бик зур рәхмәт сезгә! – диде ул.

Авыл темасына багышланган «Блогер.Татар» бәйгесендә «Иң яхшы авыл аккаунты» һәм «Авыл турында иң яхшы пост» номинацияләрендә 5әр җиңүчене бүләкләделәр. Гаилә темасына багышланган «Блогер.Татар» бәйгесендә блогерлар һәм медиашәхесләр, шәхси аккаунтлар арасыннан шулай ук 5әр җиңүче билгеләнде. Аларның барысына да 20000 сум күләмендә акчалата премия тапшырылды.

– Бу минем зур хыялым иде. Оештыручыларга, жюри әгъзаларына һәм, һичшиксез, гаиләмә зур рәхмәт әйтәсем килә. Бу бәйгедә катнашам дип уйламаган идем. Кызымның дөньяга килүе үзенә күрә бер этәргеч булды. Үзеннән-үзе кызым, гаиләм турында «Инстаграм»да постлар язып урнаштыра башладым. Бәлки, бу алга таба да әлеге эшне дәвам итүдә зур бер адым булыр, – диде өченче «Татар. Блогер» бәйгесендә җиңгән Айваз Садыйров.

Журналист Эльмира Сираҗи исә бәйгедә катнашу өчен икенче ел гариза җибәргән.

– Узган ел катнашкан идем, җиңеп булмады. Быел бәхет елмайды. Язылучы саннары, лайклары күп булмаган яшь блогерлар өчен әйбәт мөмкинлек бу. Иң мөһиме – татарча кызыклы контент, – диде ул.

Бу юлы үткәрелгән бәйгедә җиңүчеләр арасында Төркиядән Алсу Нургатина һәм Бишкәк каласыннан Нурия Шәрәфетдинова да бар иде. Нурия ханым ерак Кыргызстаннан бәйрәм тантанасында катнашучыларга видеосәламен яздырып җибәргән.

Әбисенә «Нәнәй» аккаунтын алып барырга ярдәм итүче Альбина Исмаева 20 мең сум акчаны әбисенә алып кайтып, кулына тоттырган. 86 яшьлек Фәния әби оештыручыларга күз яшьләре аша рәхмәт әйтә. Түбән Камада яшәп ятучы Ак әбине бүген 8 мең кеше укый. «Блогер.Татар» бәйгесендә җиңгәннән соң укучылары саны тагын да арткан.

Бәйгене Татарстан Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәме белән «Матбугат.ру» порталы оештыра.

Ләйсән САФИНА

Үзләреннән башка булмый

Нәтиҗә

Сәләтле балаларны – Кырымга, студентларны – М-12 төзелешенә. Лагерьларны – ремонт, «акыллы баш»ларны Google көтә. 2022 елга Татарстанның Яшьләр эшләре министрлыгы шундый ниятләр белән аяк баскан. Ә узган елның нәтиҗәләре нинди? Республиканың иң яшь министрлыгы еллык коллегиясен үткәрде.

Яшьләр сәясәтен тормышка ашыру өчен, былтыр 2 млрд 580 млн сум акча тотылган. Илкүләм проектлар да, дәүләт программалары да тулысынча үтәлгән. Бюджет акчасын кулланып кына калмыйча, грант һәм төрле бәйгеләрдә катнашу бәрабәренә, республика яшьләре Татарстанга 142 млн сум күләмдә акча китергән.

Министрлык барлыкка килгән елны ук үзенә шигарь итеп «Яшьләрдән башка яшьләр өчен бернәрсә дә булмаска тиеш» дигән сүзләрне алган иде. Тугрылыкны саклыйлар. Тимур Сөләйманов әйтүенчә, проектларны барлыкка китергәндә дә, аларны тормышка ашырганда да яшьләрнең катнашуы мөһим.

– Яшьләр сәясәте ул инде хәзер министрлык эше белән генә чикләнә торган юнәлеш түгел. Бу – яшьләрнең үз-үзләрен күрсәтү өчен мохит булдыру. Безнең бурыч – яшьләр тормышы, үсеше, ялы, аралашуы, тирә-юнен формалаштыручы юнәлешләр, яшьләрнең игътибар үзәгендә булган кешеләр белән тыгызрак хезмәттәшлек итү. Кайгырту һәм файда – яшь кеше дәүләттән менә шундый мөнәсәбәт тели, – диде министр.

Яшьләр өчен бина, яшьләр өчен мохит, яшь белгечләр җәлеп итү. Министрлык 2022 елда да шушы юнәлештә эш алып барачак. Тимур Сөләйманов сүзләренчә, быел 44 инфраструктура проектын тормышка ашыру өчен 2 млрд сум акча тотылачак. 6 яшьләр үзәген төзекләндерү нияте бар. Гомумән алганда, республикада аларның саны – 32. Моннан тыш 224 яшьләр-яшүсмерләр клубы да эшләп килә.

Төзү белән бергә, яңа биналарның кадрлар белән тәэмин ителешен дә кайгыртасы.

– Киресенчә булырга тиеш түгел. Башта бинасын төзеп, аннан шунда эшлисе кешеләре, эчтәлеге турында уйлый башлау кебек тискәре мисалларыбыз бар. Хаталарны кабатламаска өндим, – диде Тимур Сөләйманов бу җәһәттән.

Быел Баулы, Яңа Чишмә, Әтнә, Саба, Апас районнарында балалар өчен лагерьлар төзекләндереләчәк. Моннан тыш Казандагы ике лагерьда ремонт төгәлләнергә тора. Моның белән бергә 6 лагерьның юлын тәртипкә китерү каралган. Бу юнәлешкә игътибар бирүне аеруча мөһим дип саный министр.

– Лагерьда ял итү гаять зур нәтиҗә бирә ул. Бу – сәламәтлекне кайгырту да, үсеш тә, социальләшү дә. Заманча, сыйфатлы лагерьда 2–3 атна уздыру үсмернең киләчәгенә йогынты ясый ала, – ди ул. Былтыр республикадагы 200 меңләп бала бу мөмкинлектән файдаланган инде.

Сүз уңаеннан, 2022 елда Кырымда ел әйләнәсе эшли торган лагерь ачу нияте бар. Бер сменада 240лап бала ял итә алачак. Лагерь сәләтле балалар җыела торган тагын бер урынга әйләнәчәк.

Уңай яңалыклар янында күңелсезләре дә булды. Әйтик, 2021 елда балаларның «ышаныч телефоны»на мөрәҗәгатьләре бермә-бер арткан. Барлыгы 35 меңләп шалтырату кабул иткәннәр. Мөрәҗәгать сәбәпләре төрле: кемдер – мыскыллау корбаны, кайсыларының гаиләсендә тынычлык юк. Саннар да проблеманың мөһимлеген дәлилли, ди министр.

– Быел Татарстанда психологик-педагогик ярдәм үзәкләрен төзекләндерү программасы гамәлгә ашырыла башлаячак. Моңа 300 миллион сумнан артык акча тотылачак, – диде ул. – 30лап районда яшьләрнең психологик ярдәм алу мөмкинлеге юк. Республикага цифрлы психологик ярдәм хезмәте кирәк.

Акыл сату дигән сүзләрнең туры мәгънәдә ничек булганын министрлык исбатлаячак. Google компаниясе белән берлектә Яшьләр эшләре министрлыгы бу җәһәттән чара үткәрергә җыена. Аны креатив индустрияләргә (кешенең интеллектуаль эшчәнлеге белән бәйле икътисад өлкәсе. – **Ред.**) багышларга җыеналар. «Яшьләр яңа технологияләргә тиз ияләшә, үзен төрле өлкәләрдә сыный. Аларны бер-берсе белән таныштыру кирәк», – ди бу уңайдан министр.

Һөнәрдә үзеңне табу дигәндә, студентларның хезмәт отрядларын телгә алмыйча булмый. Тимур Сөләйманов әйтүенчә, министрлык студентлар отряды оешмалары белән актив хезмәттәшлек итә. Хәзер исә Юл хуҗалыгы һәм транспорт министрлыгы белән берлектә бу яшьләрне М-12 трассасы төзелешенә җәлеп итү турында уйланалар.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруга лаеклы өлеш кертүләре өчен Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Биеш авыл җирлеге башлыгы **Вәлиев** Рамил Әлфир улы, Казан шәһәр Думасы аппаратының Норматив-хокук идарәсе башлыгы урынбасары – норматив документлар эшләү һәм хокукый экспертиза бүлеге башлыгы **Ибраһимова** Әлфия Габделнур кызы, «Татарстан Республикасы «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе эш башкару идарәсенең контроль секторы мөдире **Иванова** Светлана Ивановна, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе **Камалов** Фәнис Флер улы, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының Бехтерев авыл җирлеге башлыгы **Кусаев** Николай Варламович, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Олыяз авыл җирлеге башлыгы **Маликов** Рамил Фәйзелхак улы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Круглое Поле авыл җирлеге башлыгы **Низамиева** Эльмира Роберт кызы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Тойгуҗа авыл җирлеге башлыгы **Сафин** Рәфит Әхмәтша улы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Зур Аксу авыл җирлеге башлыгы **Храмов** Алексей Васильевич, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты аппаратының опека һәм попечительлек бүлеге башлыгы **Яруллина** Рәфия Гомәр кызы **«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының мәдәни-рухи мирасын саклауга һәм баетуга зур өлеш кертүләре өчен «ТУРАН АРТ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте хезмәткәрләре: кул эшләнмәләре цехы мастеры-администраторы **Гарәфиева** Радания Рәис кызы, тегүче-технолог, кул эшләнмәләрен чигүче **Семенова** Светлана Юрьевна **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

«Биектау районының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе әйдәүче инспекторы **Бухаркина** Наталья Михайловнага; «Чаллы шәһәренең Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе әйдәүче инспекторы **Синицина** Татьяна Николаевнага; «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Биектау муниципаль районындагы «Өмет» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе директоры **Газизов** Рафис Гарәфи улына; дәүләт учреждениесе – Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсе иминиятләштерүчеләр белән үзара эшчәнлекне оештыру бүлеге башлыгы **Мелентьева** Ирина Владимировнага; дәүләт учреждениесе – Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсе Баулы районындагы клиент хезмәте (бүлек хокукындагы) җитәкчесе **Тимофеев** Станислав Николаевичка; дәүләт учреждениесе – Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсе пенсия һәм социаль түләүләр идарәсе башлыгы **Янгулова** Ирина Вячеславовнага; Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Минзәлә муниципаль районнарындагы социаль яклау бүлеге башлыгы **Мясникова** Татьяна Александровнага **«Татарстан Республикасының атказанган халыкны социаль яклау хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

Белем һәм тәрбия

ТЕАТРАЛЬ ДӘВА

МӘГЪРИФӘТ МИНИСТРЫ, ТЕАТР БАЛАЛАРНЫ ИНТЕРНЕТТАН КОТКАРАЧАК, ДИ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Россия мәгърифәт министры Сергей Кравцов балаларны интернеттан читләштерү ысулын тапкан. Аның фикеренчә, бу мәсьәләдә мәктәп театрлары ярдәмгә килергә мөмкин. Театр, чыннан да, бәйлелектән коткара алырмы?

«Балаларның психологиясе 7 яшьтән формалаша. Алар белән аралашырга, уйнарга, шөгыльләнергә кирәк. Әгәр әти-әни шуларга игътибар итмәсә, киләчәктә мөнәсәбәтләрне җайлау авыр булачак. Балалар һәрберсе яхшы булып туа, аларны олылар үзгәртә. Әгәр өйдә, мәктәптә аңламыйлар икән, проблемалар килеп туа һәм бу фаҗигагә китерергә мөмкин», – ди министр.

Ләйсән Соколова Казандагы 2 нче гимназиядә белем ала. Кечкенәдән театр, кино түгәрәкләренә йөргән ул. Тик имтиханнарга әзерләнәсе бар дип, аны ташларга мәҗбүр булган. Балалар спектакльләрендә төрле хайван рольләрен башкарган. «Үксез»ләр дигән кинода усал кыз – Ралинә ролендә төшкән иде.

– Дөрестән дә, түгәрәкләргә йөргәндә, интернетта утырырга вакыт калмый иде. Рухны ныгытуда да, зәвык тәрбияләүдә дә файдасы зур аның. Имтиханнарга өйрәнергә авыр булгач, яраткан шөгылемне ташларга туры килде. Кызганыч, 9 нчы сыйныфтан соң театр училищесына укырга керә алмадым. Мәдәният институтына барырга хыялланам, – ди Ләйсән.

Казандагы 16 нчы татар-инглиз гимназиясенең «Нур» татар театры җитәкчесе Роза Ибятова да, театр түгәрәге интернеттан биздерә ала, дип саный. Түгәрәктә 100гә якын бала шөгыльләнә. Аны тәмамлаучылар бүген республиканың төрле театрларында уйный.

– Балалар һәрвакыт кызык эзли. Әгәр без кызыксыну уята алсак, интернет икенче планга калачак. Телефонда утырырга вакыт тимәячәк. Мәктәп җитәкчелеге кирәк дип тапмаса, түгәрәкне 25 ел буе алып барып булмас иде. Мондый түгәрәкләрне һәр мәктәптә оештырырга кирәк. Моның өчен зур чыгымнар кирәкми. Бөтен бала да математик, химик, физик була алмый, әмма чын кеше булырга һәркемнең хакы бар, без аны тәрбияләргә тырышырга тиеш, – ди Роза Ибятова. – Актерлык осталыгы, сәхнә теленә өйрәтәм. Театр сәнгатенең беренче алымнары белән 1 нче сыйныфтан ук кызыксына башлыйлар. Балалар бер-берсен уздырып, төрле образларга керергә тырышалар, үзләрендә җаваплылык тоялар. Берәр хайванны күрсәтегез әле, дим. Бу аларның дөньяга карата күзәтүчәнлеген арттыра. Тәрбиясе аксаган балалар да яхшылыкка тартыла. Тукай юкка гына: «Театр яктылыкка, нурга илтә, кире юлга җибәрми, уңга илтә», – дип әйтмәгәндер. Бу сүзләр бүген дә дөнья бәясе торырлык. Башлангыч сыйныф укучылары спектакль карарга тамашачы буларак килә, аннан соң укытучылары белән әсәрне бергәләп анализлый. Безгә язучы, шагыйрьләр дә еш килә. Аларны күргәч: «Ә, бу теге китапны язган абыймы?» – дип кызыксыналар. Казандагы театрларга йөрергә яратабыз. Тел бетә, дип карап торсаң, бетә инде ул. Әгәр дә һәр кеше, һәр укытучы үз өлешен кертсә, тел дә, мәдәният тә сакланачак. Бәйгеләрдә катнашып, җиңүләр яулыйбыз.

Минзәлә районы гимназиясендә «Сәяр» түгәрәге эшли. Анда 80гә якын бала йөри.

– Театр, беренчедән, телгә, тәрбиягә, икенчедән, үз-үзеңне сәхнәдә тоту серләренә өйрәтә. Абыйлары түгәрәккә телефон белән кертми. Өлкән сыйныф укучылары кичен өчәр сәгать шөгыльләнә. Онлайн бәйгеләргә әзерләнәләр. Аларның интернетта утырырга вакытлары да юк. Минем дә балам йөри. Алар, видеоролик төшереп, төрле бәйгеләрдә катнашалар. Интернетны файдалы максатларда кулланалар, – ди директор Гөлназ Хәлиуллина.

Сәрия МИФТАХОВА

Спорт

rubin-kazan.ru

Яратып китеп кара

«Казан – тискәре шәһәр». «Рубин» белән саубуллашып, бер көн узгач, серб футболчысы Джордже Деспотович Татарстан башкаласы турында әнә шундый фикер җиткерде. Казанда уйнап киткән спортчылар күп булды, шул исәптән дөнья күләмендә танылганнары да, әмма болай ук кыланганнары юк иде.

Джордже Деспотовичның «Рубин»нан китүен Казан клубы рәсми рәвештә якшәмбе кичендә җиткерде. Хәер, шулай буласы алдан ук билгеле иде. Серб футболчысы Казанда уйнамаячагын әле ике атна элек үк хәбәр итте. Шул ук көнне «Рубин»ның футболчыны яшьләр командасына күчерүе һәм үзенә яңа клуб эзләргә рөхсәт бирүе билгеле булды. Бер караганда, була торган хәл. Әмма вакыйгалар агышы көтелмәгәнчә дәвам итте. Футболчы вәкиле Деспотовичның Казаннан китәргә җыенмавын, ә килешүдәге шартларны ахырына кадәр үтәргә җыенуы турында әйтте. Аңлашыла инде, кемнең үзе теләп акчадан баш тартасы килсен?! Серб футболчысы исә, рәсми булмаган мәгълүматларга караганда, «Рубин»да иң зур хезмәт хакы алган уенчы булып саналды. Ахыр чиктә мәсьәлә хәл ителде һәм яклар тыныч кына саубуллашырга килешкән. Дөрес, Казан клубының спорт директоры Олег Яровинский сүзләреннән аңлашылганча, футболчы китәргә үзе теләк белдергән. «Без аңа каршы килмәдек. Ничек кенә булмасын, ул үз исемен клуб тарихына язып калдырды. Узган сезон Деспотович өчен гомумән иң яхшысы булгандыр. Ул командага нык булышты», – дигән Олег Яровинский.

2020 елның җәендә Оренбургтан күчеп килгән Джордже Деспотович беренче сезонда ук «Рубин» составында 14 туп кертте һәм команданың премьер-лигада дүртенче урын алуына зур өлеш кертте. Серб футболчысы уен кырында гына түгел, башка вакытта да тик утырмады. Үзенә игътибар җәлеп итәргә тырышты. Әйтик, ул үзен «Барселона»да чыгыш ясарлык уенчы дип атап, Каталония клубына хат язганын игълан итте. Гаҗәп түгел, мондый вакыйгалар тамашачыны да җәлеп итә. Шуңа күрә Деспотович җанатарлар өчен иң якын иткән уенчыларның берсенә әверелде.

Ләкин мәхәббәт белән нәфрәт арасы бик якын. Торабара серб егетнең уеннан уймак чыгара торган гадәте дә ачыкланды. Нибары бер туп керткән футболчы быел көз социаль челтәрләрдә язышканда артыгын кыланып атты. Аның ни өчен уйнамаганын, кайда булуын сораган тамашачыга футболчы болай дип җавап бирде: «Синең әниең белән». Мондый сүзгә җанатарларның мөнәсәбәтен чамалавы кыен түгел. «Рубин»да исә вакыйга зурга китмәсен өчен махсус акция игълан иттеләр: футболга әнисен алып килгән кешегә бушка билет өләштеләр.

«Барыгызга да Казанда уздырган матур көннәр өчен рәхмәт әйтәм», – дип язды моннан ике атна элек Деспотович социаль челтәрдәге сәхифәсендә. Дүшәмбе көнне исә җанатарлары белән туры эфир уздырганда Казанны «тискәре шәһәр» дип атады. Фикер үзгәрү акча белән дә бәйле булырга мөмкин. Алай икән, «Рубин»ның мондый уенчыдан вакытында котылырга тырышуы гаҗәп түгел.

Илнар ХӨСНУЛЛИН

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты, әтисе

ЯМАЛНИЕВ Мирзага Хәертдин улы

вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе баш киңәшчесе Ямалниев Илнур Мирзага улының авыр кайгысын уртаклаша.



«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ

(843) 222-09-65, 222-09-70. E-mail: vtreklama@mail.ru

«КЫЗЫЛ ЗОНА»ДА ЭШЛӘҮЧЕ РЕГИНА КОРБАНОВА:

«ЧИРДӘН ТҮГЕЛ, ХАТАДАН КУРЫКТЫМ»

Рәхмәт, табиб!

Алар кабат күренмәс дошман белән көрәшнең нәкъ үзәгендә. Өченче ел инде тәҗрибәле табиблар белән иңне-иңгә куеп, яшь булачак медицина белгечләре коронавирус белән көрәштә үз өлешләрен кертә. Башкаланың «кызыл зона»ларының берсендә эшләүче Регина КОРБАНОВА белән «таҗ»лы чорның авырлыклары, вакцина ясатуның әһәмияте турында сөйләштек. Казан федераль университетының фундаменталь медицина һәм биология институты студенты, булачак табиб-гастроэнтеролог ул.

Регина Корбанованың шәхси архивыннан

«Авыр булачак, дидем»

Регина Республика клиник йогышлы авырулар хастаханәсендә 2021 елның ноябреннән эшли. Яшерми: беренче вакытта курку хисе дә булмаган түгел.

– Тик мин чир йоктырырмын дип түгел, хата ясармын дип курыктым, – ди ул. – Моңа кадәр ныклап торып шәфкать туташы булып эшләгәнем юк иде бит әле. Өченче курста практика узган вакытта кан тамырыннан кан алганым булды – шуның белән шул. Үземә: «Авыр булачак», – дидем. Әмма эшемне башкарып чыгасыма шикләнмәдем. Миңа кан алырга да, катетер куярга да өйрәнергә кирәк иде. Бәхеткә, яхшы коллективка эләктем, шәфкать туташлары ярдәм итте.

Гадәттә, медицина юлына бу өлкәгә азмы-күпме катнашы, кызыксынуы булганнар баса. Регинаның гаиләсендә дә бар андыйлар. Әнисе – «ашыгыч ярдәм» фельдшеры, әбисе дә – медицина белгече.

– Табиб булырмын дип хыялландым. Һөнәр сайлар вакыт җиткәч тә, кем булырга теләвемне анык белдем. 10 нчы сыйныфта укыганда биология фәненә кызыксыну уянды. Ләкин бу өлкә буенча китсәм, эш таба алырмынмы икән, дигән шик уянды. Ә табиблар гел кирәк бит, – дип искә ала Регина.

Оясында күргәннәре үзенекен иткән, димәк. «Әнинең эшендә еш була, аның медицинага бәйле китапларын актара идем. Алар миңа алар бик кызык тоелдылар. Аңа еш кына таныш-белешләре киңәш сорап шалтыратты. Ул гел кешеләргә булышты. Минем дә кешеләргә ярдәм итәсе, файдалы буласым килде. Еш кына әни кире уйларга куша иде. Кешеләрнең күп очракта рәхмәтсезрәк, ә хезмәтнең рухи яктан кыен булуын искәртеп торды. Барыбер бу юлны сайладым. Университеттан китәргә теләгән чаклар булса да, хәзер мин бер дә үкенмим!» – ди Регина.

«Кызыл зона»да эшләвемне хупладылар»

– Коронавирус башланганда, әти көн саен хәбәрләр карый һәм минем, башка медиклар кебек үк, бу чир белән көрәшүемне тели иде. Тели дә, шул ук вакытта курка да иде. Бәлки, «кызыл зона»да эшли башлавымның тагын бер сәбәбе дә шулдыр – мин дә әти-әниемнең кызлары белән горурлануын теләдем! – ди Регина. – Гәрчә сәламәтлегем өчен борчылсалар да, якыннарымның барысы да минем «кызыл зона»да эшләвемне хуплады.

Кеше нәрсәгә дә, нинди шартларга да ияләшә анысы, табигате шундый. Тик менә бүген җир җимертеп торган кешенең иртәгә инде сулып баруын күзәтү авыррак. Регина да:

– Иң авыры – сырхауның бүлеккә яхшы хәлдә, оптимизм тулы, юмор хисле булып керүен, ә икенче сменага килгәндә аны реанимациягә алып китүләрен күрү. Бу бит барысы да бик кыска вакыт эчендә! – ди.

Үзе өчен курку юк инде хәзер әңгәмәдәшебезнең. Тик менә якыннары өчен борчыла.

– Казанда яшәүче әбиемә чир йоктырырмын төсле. Шуннан куркам. 2021 елның сентябрендә коронавирусны бик авыр кичерде. Шулай туры килде: ул яткан бүлеккә эшкә килдем. Хәзер тагын чирләмәсен дип борчылам, – ди Регина.

Иң мөһим киңәшләр

Яшь булса да, инде тәҗрибә туплап өлгергән ак халатлы шәфкать иясеннән киңәшләр дә сорамый мөмкин түгел, билгеле. Алар бик гади, әмма гаять мөһим.

– Вакцина ясатырга кирәк. Мин вакциналы кешеләрнең чирне җиңелрәк кичергәннәрен үз тәҗрибәмдә дә күрдем. Соңрак вакцинасызлар, кислород җитешмәүдән интегеп, прививка кадатмавына ничек үкенгәнен күргәнем бар… – ди Регина. – Хастаханәгә эләкмәс өчен, кайбер кагыйдәләрне истә тотсыннар иде. Ашауга игътибар бирергә кирәк. Әйтик, күбрәк су эчәргә, җиләк-җимеш, яшелчәләр ашарга. Кулларны ешрак юарга, бүлмәләрне җилләтергә, җыештырырга онытмаска. Үзегез белән гел антисептик йөртегез. Җәмәгать урыннарында, концертларга йөрүдән чикләнеп торырга иде. Битлек киюне онытмаска, аның респираторлысы яхшырак. Начар гадәтләрегез бар икән, әйтик, тәмәке тартасыз, ди, алардан котылырга кирәк. Кальян тартмау хәерле. Гомумән, сәламәтлекне кадерләргә кирәк.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

КОЯШ НУРЫ КЕБЕК СИН

Кечкенә дә төш кенә

Кайбер балалар кояш нуры кебек. Алардан бөркелгән җылылык хәтта тирә-юньдәге өлкәннәргә дә җитә. Нәфис гимнастика белән шөгыльләнүче 11 яшьлек Казан кызы Агния Зиятдинова да шундыйлардан. Ул мине спортта ирешкән уңышлары белән генә түгел, күбрәк дөньяга карашы, бәләкәй генә булса да, анык фикер йөртүе белән җәлеп итте. Бүген кыз тренер Вероника Скабина белән «Ватан» спорткомплексында шөгыльләнә.

Соңгы араларда Агния җиңү артыннан җиңү яулый. Алар арасында «Сөембикә кубогы», «Золушка», «Sport Kids» турнирларындагы беренчелекләр бар.

– Минем өчен алтын җиңү Санкт-Петербургта «Diva cup» бөтенроссия турнирында булды, – дип уртаклаша кыз кичерешләре белән. – Анда җиңүемне белгәч, хәтта үз-үземә ышанмый тордым. Күкнең җиденче катында булдым дип әйтәләр бит әле. Мин дә шундый хисләр кичердем.

Шатлана, әмма уңышлардан башы әйләнми Агниянең.

– Күнегүләр вакытында хаталар ясасам да, кайберәүләр кебек елап утырмыйм. Киресенчә, әһә, монысы барып чыкмады, димәк, тырышырга кирәк дигән нәтиҗә ясыйм. Шыңшып утырудан бернинди файда юклыгын беләм чөнки. Ялгышларыңны төзәтә алсаң гына алга барып була. Мин гимнастиканы уңайлы спорт төре дип әйтмәс идем. Бик катлаулы ул. Әмма бу авыр юлны мин үзем сайладым. Шуңа күрә үземә генә ышанырга туры килә. Бик күп республика, Россия буенча үткәрелгән ярышларда катнаштым инде. Мәскәүдә һәм Кырымдагы Евпатория шәһәрендә Евгения Сиротина җитәкчелегендә җыеннарда булдым. Осталыгымны арттырыр өчен теләсә нинди мөмкинлектән файдаланырга тырышам.

Агния гимнастика белән шөгыльләнүче спортчылар турында да күп белә.

– Миңа Александра Солдатова ошый. Ул карьерасын тәмамлады, зур спорттан китте инде. Бик үзенчәлекле спортчы иде, – ди ул. – Вакыт булганда, нәфис гимнастика буенча ярышларны карарга бик тә яратам. Нинди дә булса яңалык күрәсе, өйрәнәсе килә. Әмма шул ук вакытта беркемгә дә охшарга тырышмыйм. Һәр җирдә, һәр ярышта үзем булып каласым килә.

Агниянең алга барырга омтылам дигән сүзе гимнастикага гына кагылмый әле.

– Спорт белән шөгыльләнү мәктәптә укырга бер дә комачауламый. Музыка мәктәбендә фортепианода уйнарга да өйрәнәм. Икесендә дә гел «5ле»гә генә укыйм, – дип таныштыра ул үзе белән.

Бу сүзләрне сыйныф җитәкчесе Сания Абдуллина да җөпли:

– Бер булганнан барысы да була дип юкка гына әйтмиләр, күрәсең. Агния оригиналь фикер йөртә, бөтен нәрсә белән кызыксына. Рус теле һәм әдәбияты, математика фәннәреннән олимпиадаларда катнашып, җиңү яулый. Сүз дә юк, бик талантлы кыз.

instagram.com

Мәктәп турында сүз чыккач, Агния дуслары турында да сөйләп ала.

– Дүрт сыйныфны һәм 5 нче сыйныфның бер чиреген бер мәктәптә укыдым. Аннан икенче мәктәпкә күчәргә туры килде. Элеккеге сабакташларым белән һаман элемтәдә торабыз. Хәзергеләре белән дә дуслашып беттем.

Җор телле ул, бер дә аптырап калмый. Аның белән дусларына да бик рәхәттер. Үзенең спортчы булып китүен дә мәзәк итеп кенә сөйли.

– Гимнастика белән шөгыльләнәчәгем алдан ук билгеле булган. Әнине УЗИга төшергәндә, табиб, кызыгызның аяклары бик озын, спорт белән шөгыльләнсә, зур уңышларга ирешер, дип юраган. Әни, бәлки, моңа бик игътибар итмәгән дә булыр иде. Мин бик шук булганмын. Гел йөгереп йөргәнмен, сикергәнмен, көлгәнмен, елмайганмын. Нииндидер күнегүләр ясарга тырышканмын, хәтта шпагатка да утырганмын. Шуннан мине, рәхәтләнсен әйдә, энергиясен чыгарсын дип, гимнастикага бирергә булганнар. Бу вакытта миңа 4 яшь тулып кына киткән була әле.

Әти-әнисен гаҗәпләндерүдән бер дә туктамый Агния.

– Бик акыллы, зиһенле ул, – ди әнисе Ландыш. – Яшерен-батырын түгел, бәләкәй генә булса да, фикеренә таянып, кызымнан үрнәк алган чакларым да була. Аның беркайчан да киреләнгәнен, елый-елый нәрсәдер даулаганын хәтерләмим. Шундый яхшы кәефле, позитив кеше ул: нинди генә вазгыять килеп туса да, бары тик яхшы якларны гына күрергә тырыша. Гел кемгәдер ярдәм итәргә омтыла. Аның өчен бу дөньяда, әйтерсең лә, усаллык дигән нәрсә бөтенләй юк. Һәр җирдә матурлык кына күрә. Нииндидер тәрбия ысуллары кулланам дип әйтә алмыйм. Бер генә нәрсә әйтә алам: мин аны бик нык яратам. Бу хисләремне беркайчан да яшергәнем юк. Өч яшькә кадәр нәрсә теләсә, шуны эшләргә рөхсәт иттем. Әйтергә кирәк, мондый адымны күп әти-әниләр аңлап бетерми. Ни теләсә, шуны эшләргә рөхсәт итү ул – куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәү, шартлар тудыру дигән сүз. Мәсәлән, безнең өйдә барлык розеткалар да «ябык», димәк, баланың кулы җитми дигән сүз. Шулай икән, димәк, моны эшләргә ярамый дигән уй баланың башына үзеннән-үзе кереп урнаша. Без аның теләкләрен дә үз иркенә куйдык. Бүген үзен берәр башка өлкәдә сынап карыйсы килсә, каршы килмәс идем.

Әтисе Тимерхан да шатланып туя алмый кызының уңышларына:

– Телефоннан Санкт-Петербургта уздырылган турнирда беренче урын яулаганын ишеткәч, шатлыктан күз яшьләрем тәгәрәп төште. Ике тәүлек эйфория халәтендә йөргәнмендер. Җентекле эш һәрвакытта да үз җимешләрен бирә дип уйлыйм. Әти-әниләргә шуны әйтәсем килә: үзегез белмәгән яки эшләп карамаган әйберне балаларга өйрәтеп маташмагыз. Бала күңеле аның дөрес түгеллеген барыбер сизенә. Берәр нәрсәгә омтылышы булса, профессионаллар кулына бирү – иң кулае. Тик бу очракта да читтән күзәтүче булып кына калырга һич тә ярамый. Үзеңә дә балага үрнәк булырга, җитешсезлекләрне бетерергә кирәк.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар: ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7080 данә
Гомуми тираж – 17126 данә

Газетага сертификат бирелде

Заказ 214

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).

16+